Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге Советы

КАРАР

"16" 03.2020 ел.

№ 104

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегендә 08.08.2018елның 74 номерлы муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә" (үзгәрешләр белән,20.02.2019 № 87В, 20.06.2019 № 87Б, 26.12.2019 №99) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Советының 03.07.2018 елның 56 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 16 статьяның 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы белән, шул исәптән, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма белән (сәяси партия, һөнәри берлек органы белән, шул исәптән, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре Советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г). муниципаль берәмлек идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) түләүсез нигездә тәкъдим итү (муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә);

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;».

1.2. 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктчасы белән өстәргә:

"2.1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә; ".

2. 32 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Дисциплинар җәзаләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

3. 33 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елның 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган җәзаләр, муниципаль хезмәткәрнең эшкә сәләтсезлеге чорларын, отпускта булу чорларын исәпкә алмаганда, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупцион хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми".

4. Әлеге карарны Урмандеево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе, Урмандеево авыл җирлеге башлыгы В.З.Николаев